| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19.09.2019 № 852

Нурлат муниципаль районы территориясендә эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряд төзү турында

Россия Федерациясенең «Ветеринария турында»гы 14.05.1993 ел, № 4979-1 Законы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 ел, 30 март, 52-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, кеше һәм хайваннар өчен уртак булган аеручa куркыныч авырулар чыганакларына каршы көрәш һәм профилактика максатларында, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Нурлат муниципаль районы территориясендә эпизоотиягә каршы даими әзерлекнең җыелма мобиль отрядын булдырырга.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

- 1нче кушымта нигезендә Нурлат муниципаль районының эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряды (алга таба – Отряд) турында нигезләмә;
- 2 нче кушымта нигезендә отрядның оештыру-штат структурасы;
- 3 нче кушымта нигезендә отрядның күләме буенча составы;
- 4 нче кушымта нигезендә отряд составына кертелә торган автомобиль техникасы исемлеге;
- 5 нче кушымта нигезендә төркем командирларына эш һәм эш вакытыннан тыш хәбәр итү схемасы;
- 6 нчы кушымта нигезендә район дәүләт ветеринария берләшмәсенең отряд төркемнәренең командирларына хәбәр итү һәм җыю буенча кизү торучысының инструкциясе.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Нурлат муниципаль районы буенча авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгына йөкләргә (килешү буенча).

Җитәкче Л.Н.Маняпов

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 19 сентябрендәге 852 номерлы карарына
1 нче кушымта

# Нурлат муниципаль районының эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряды турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Нурлат муниципаль районы территориясендә эпизоотиягә каршы даими әзерлектәге җыелма мобиль отрядны (алга таба – Отряд) оештыру һәм эшләтү тәртибен билгели.

1.2. Отряд штаттан тыш бүлек булып тора һәм Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән, кеше һәм хайваннар өчен уртак аеруча куркыныч авырулар чыганакларына каршы көрәш һәм профилактика һәм биологик-социаль характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы белән бәйле, моның сәбәбе хайваннарның аеруча куркыныч авырулары булган мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән максатларда төзелә.

1.3. Отряд үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә, "Ветеринария турында" 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законына, "Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында" 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясенең Баш дәүләт ветеринария инспекторы тарафыннан расланган биологик калдыкларны җыю, утильләштерү һәм юк итү буенча ветеринария-санитария кагыйдәләренә, кеше һәм хайваннар өчен уртак булган куркыныч авырулар чыганакларын профилактикалау һәм бетерү мәсьәләләре буенча кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең башка норматив-методик документлары, Нурлат муниципаль районы башлыгы боерыклары һәм карарлары, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары һәм боерыкларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.4. Отряд килешү буенча «Нурлат район дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ, Россия Эчке эшләр министрлыгының Нурлат районы бүлеге, шулай ук "Нурлат үзәк район хастаханәсе" ДАССО, «ТКХ ИК» МУП, «Татарстан Республикасының Нурлат һәм Аксубай районнарында гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФБССОның филиалы һәм җирле үзидарә органнары вәкилләре һәм белгечләреннән формалаша.

1.5. Отрядның шәхси составы кирәкле профилактик вакцинацияне вакытында үтәргә тиеш.

## 2. ОТРЯДНЫҢ БУРЫЧЛАРЫ

2.1. Отряд кеше һәм хайваннар өчен уртак булган аеруча куркыныч авырулар чыганакларына каршы профилактика һәм көрәшү максатларында төзелә, һәм биологик-социаль характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы һәм барлыкка килү белән бәйле мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән.

2.2. Отрядның бурычлары этаплап билгеләнә:

беренче этап-авыруның төрен (яки хайваннар авыруының һәм үлеменең сәбәпләрен) билгеләгәнчегә кадәр;

икенче этап-авырып китүчедә авыру төрен ачыклаганнан һәм ахыргы диагноз куелганнан соң.

2.2.1 Беренче этапта отрядның бурычлары:

– ветеринария һәм медицина разведкаларын гамәлгә ашыру;

– эпидемиология һәм эпизоотик хәлне бәяләү;

– контактта булган, зәгыйфьләнгән һәм авыру хайваннарны (алга таба-авыру хайваннар) аерып алу;

– клиник авырулы, һәлак булган хайваннарның патологик материалын сайлап алу;

– вирусологик тикшеренүләр һәм дифференциаль диагностика уздыру өчен махсуслаштырылган лабораторияләргә пробалар китерү;

– хайваннарны аерып алганнан соң җиһазларга, инвентарь һәм бүлмәләргә агымдагы һәм йомгаклау дезинфекцияләүне үткәрү;

– бинада һәм территориядә механик чистарту үткәрү.

2.2.2. Икенче этапта отрядның бурычлары:

– карантин зонасында керү-чыгу режимын тәүлек буе контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;

– карантин зонасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү;

- карантин зонасындагы халык арасында профилактик һәм эпидемиягә каршы чаралар үткәрү;

– эпизоотик чыганактагы барлык авыру хайваннарны аулау һәм сую(чалу);

– үлгән(чалынган) хайваннарны утильләштерү (юк итү) урыннарына илтү һәм чыгару;

– чалынган хайваннар мәетләрен юкка чыгару;

– эпизоотик чыганакны бетерүдә катнашучы отрядның һәм башка затларның шәхси составын санитар эшкәртү;

- бер тапкыр кулланыла торган саклану чараларын юк итү;

– дезинфекция буенча барлык чаралар комплексын үткәрү;

– хайваннардагы аеруча куркыныч авыруларны бетерү максатларында үткәрелә торган чараларның кирәклеге һәм максатчанлыгы турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша халыкка хәбәр итү.

## 3. ОТРЯДНЫҢ ОЕШТЫРУ СТРУКТУРАСЫ, БУРЫЧЛАРЫ ҺӘМ БҮЛЕКЧӘЛӘРЕНЕҢ ҖИҺАЗЛАНДЫРЫЛУЫ

3.1. Отрядның командиры һәм шәхси составы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән билгеләнә. Отрядның командиры булып «Нурлат район дәүләт ветеринария берләшмәсе»ДБУ башлыгы тора.

3.2. Отряд төп бүлекчәләрдән һәм тәэмин итү бүлекчәләреннән тора.

Төп бүлекчәләр:

– ветеринария разведкасы төркеме;

– хайваннарны аулау һәм юк итү төркеме;

– хайваннарның үләксәләрен яндыру төркеме;

–дезинфекцияләү төркеме.

Тәэмин итү бүлекчәләре:

– медицина һәм эпидемиологик разведка төркеме;

– үткәрү –чыгару режимын тәэмин итү төркеме;
– җәмәгать тәртибен саклау төркеме;
– табиб-шәфкать туташлары бригадасы;
– янгын сүндерү бүлекчәсе;
– санитар эшкәртү пункты.

3.3. Ветеринария разведкасы төркеме үлгән (авырулары ачыкланган) хайваннарны ачыклау (табу) урынына чыгып, патологик материал сайлап алуны (инструкция нигезендә кан сүлен, патологик материал һәм биоматериалны сайлап алу тәртибе буенча), аны махсуслаштырылган лабораториягә илтүне (тикшеренү өчен пробалар бирү тәртибе нигезендә) һәм үлгән хайваннарны ачыклау (табу) урынына барып янәшәдәге ишегалларны һәм территорияләрне әйләнеп чыгуны (тикшерүне) башкара, һәлак булган хайваннарны исәпкә алуны алып бара.

Ветеринария разведкасы төркеме даими әзерлек режимында тора һәм хайваннарның үлү (авыру) очраклары турында мәгълүмат алганнан соң бер сәгать эчендә урынга чыга.

Ветеринария разведкасы төркеме район дәүләт ветеринария берләшмәсе хезмәткәрләре арасыннан формалаша. Ветеринария разведкасы төркеме командиры отряд командиры урынбасары булып тора.

Ветеринария разведкасы төркеменең шәхси составы шәхси саклану костюмнары, сулыш органнарын саклау чаралары белән тәэмин ителә.

Төркемне җиһазлау: авыру хайваннарны аулау өчен кирәк-яраклар, патологик материалны алу өчен махсус инструментлар, патологик материалны алып килү өчен кирәк булган термоконтейнер, лабораториягә патологик материалны юнәлдерүнең бланклары, мобиль элемтә чаралары, полиэтилен капчыклар, дезинфекция чаралары, су салынган (5 литрдан да ким түгел) кул юу өчен савыт, сөлге, сабын, бинокль, фонарь, һәлак булган хайваннарны исәпкә алу журналы.

3.4. Малларны тоту һәм юк итү төркеме авыру хайваннарны аулый, хайваннарны кан чыгармыйча юк итү чараларын башкара, аларны җыю һәм транспортка төяү буенча чаралар үткәрә, үлгән хайваннарның санын исәпкә ала.

Терлекләрне аулау һәм юк итү төркеме район ветеринария берләшмәсе, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре арасыннан формалаша.

Төркемнең шәхси составы шәхси саклану костюмнары һәм сулыш органнарын саклау чаралары белән тәэмин ителә.

Төркемне җиһазлау: хайваннарны тоту өчен кирәк-яраклар, полиэтилен капчыклар, хайваннарны йоклату өчен чаралар, автомат шприцлар, үтерелгән хайваннарны исәпкә алу журналы һәм дезинфекция чаралары.

3.5. Үлгән хайваннарны яндыру төркеме яндыру өчен урынны әзерли, хайван үләксәләрен бу урынга китереп бушата, дезинфекция чараларын кулланып, биотермик чокырларда аларны юк итә яки янгын куркынычсызлыгы һәм шәхси куркынычсызлык чараларын катгый үтәп яндыру юлы белән юкка чыгара, яндырылган хайваннарны исәпкә ала.

Хайван үләксәләрен яндыру, юк итү төркеме район дәүләт ветеринария берләшмәсе, «ТКХ ИК» МУП, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре арасыннан формалаша.

Ветеринария-санитария экспертизасы лабораториясенең яндыру, юк итү төркеме составыннан ветеринария табибы ит һәм ит продуктларына ветеринария-санитария

экспертизасы кагыйдәләре нигезендә терлек чалу продуктларына ветеринария-санитария хәлен бәяләүне, чалынучы терлекләрне карауны уздыра.

Төркемнең шәхси составы саклау костюмнары, сулыш органнарын саклау чаралары, резина перчаткалар белән тәэмин ителә.

Төркемне җиһазлау: экскаватор һәм металл кузовлы йөк автомобиле (яки металл арбалы автомобиль), дезинфекция чаралары, утильләштерелгән хайваннарны исәпкә алу журналы.

3.6. Дезинфекция төркеме авыруларны ачыклау урынын механик чистарту, йогышлы авыру чыганагына агымдагы һәм йомгаклау дезинфекциясен (ветеринария дезинфекциясе, дезинвазия, дезинсекция һәм дератизация үткәрү инструкциясе нигезендә) үткәрә. Дезинфекция төркеме «Нурлат район дәүләт ветеринария берләшмәсе»ДБУ хезмәткәрләреннән формалаша.

Төркемнең шәхси составы саклау костюмнары, сулыш органнарын саклау чаралары, резина перчаткалар белән тәэмин ителә.

Төркемнең җиһазланышы: Комаровның дезинфекцион җайланмасы һәм дезинфекция чаралары.

3.7. Медицина һәм эпидемиология разведкасы төркеме гамәлгә ашыра:

– эпидемия учагында медицина һәм санитар-эпидемиологик разведка һәм күзәтчелекне уздыру;

–авыру табылган җирдә яшәүче халыкка һәм куркыныч йогу мөмкин саналган төркем затларына (эпизоотия чыганагын бетерүдә катнашкан отрядның һәм башка катнашучыларның шәхси составы) медицина каравы үткәрү;

– авыручыларны (авыруга шик белән булганнарны) ачыклау максаты белән йортларны йөреп чыгу һәм авырулар белән аралашучыларны һәм контакт дәрәҗәсен билгеләү;

– Республиканың махсуслаштырылган лабораторияләренә лаборатор тикшеренүләр өчен материал сайлап алу һәм китерү;

– ашыгыч профилактиканы оештыру һәм ашыгыч профилактиканы үткәрү артыннан контроль булдыру;

– авыруга шик туган кешеләрне, авыручыларны вакытлыча изоляцияләү;

– эпидемия урынында агымдагы һәм йомгаклау йогышсызландыруны үткәрү һәм контрольдә тоту;

- отряд командирына разведка мәгълүматларын тапшыру.

Медицина һәм эпидемиология разведкасы төркеме "Нурлат үзәк район хастаханәсе" ДАССОның һәм «Татарстан Республикасы гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФБССОның Нурлат һәм Аксубай районнарында филиалы хезмәткәрләреннән формалаша.

Медицина һәм эпидемиология разведкасы төркеменең шәхси составы саклау костюмнары, сулыш органнарын саклау чаралары, резина перчаткалар белән тәэмин ителә.

Төркемне җиһазлау: лаборатория тикшеренүләре өчен материал алу өчен җиһаз, табиблар өчен җиһаз.

3.8. Үткәрү режимын тәэмин итү төркеме карантин зонасында хәрәкәтне оештыру һәм җайга салуны тәэмин итә. Төркем контроль-үткәрү постларыннан һәм патруль-пост хезмәте постларыннан тора. Постлар саны карантин зонасына керү (чыгу) саны белән билгеләнә.

Төп керү урыннарында (карантин зонасына) контроль-үткәрү постлары, икенче урында – патруль-пост хезмәте постлары булдырыла.

Үткәрү-чыгару режимын тәэмин итү төркеме Россия Эчке эшләр министрлыгының Нурлат районы буенча бүлеге, юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе һәм «Нурлат район дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ хезмәткәрләреннән формалаша.

Контроль-үткәрү постын җиһазлау: җиңел автомобиль, мобиль элемтә чаралары, дезинфекция барьеры, шлагбаум, кешеләрнең киемнәрен алыштыру урыны, Комаров дезинфекцияләү җайланмасы яки транспорт чараларын юу һәм дезинфекцияләү өчен махсус техника, махсус эремәне әзерләү өчен савыт, су савыты, дезинфекция чаралары, юынгыч, сөлге, сабын, "Карантин"язулы аншлаг.

Патруль-пост хезмәте постын җиһазлау: җиңел автомобиль, мобиль элемтә чаралары, шлагбаум, "Карантин" язулы аншлаг, карантин зоналарын әйләнеп үтүне күрсәтә торган юл билгеләре, фонарь.

Үткәрү режимы төркеменең шәхси составы саклау костюмнары, сулыш органнарын саклау чаралары, итекләр, резина перчаткалар белән тәэмин ителә.

3.9. Җәмәгать тәртибен саклау төркеме карантин зонасында хокук тәртибен саклауны тәэмин итә, отрядның шәхси составын, беренче чиратта, авыру хайваннарны аулау һәм юк итү төркемнәрен, медицина һәм эпидемиология разведкасы төркемнәрен озатып баруны һәм саклауны оештыра.

Җәмәгать тәртибен саклау төркеме Россия Эчке эшләр министрлыгының Нурлат районы буенча бүлеге хезмәткәрләреннән формалаша.

Төркемнең шәхси составы корал һәм саклану штат чаралары белән тәэмин ителә һәм җиһазландырыла.

3.10. Табиб-шәфкать туташлары бригадасы карантин-чикләү чараларын уздыру чорында халыкка кичектергесез медицина ярдәме күрсәтә, ачыкланган авыручыларны йогышлы авырулар бүлегенә госпитализацияләүне оештыра.

Табиб-шәфкать туташлары бригадасы «Нурлат үзәк район хастаханәсе»ДАССОның хезмәткәрләре арасыннан формалаша.

Бригаданың шәхси составы саклагыч костюмнар, халатлар, башлык, кием-салым һәм битлекләр белән тәэмин ителә.

Бригаданы җиһазлау: Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрлыгының җитәкче документлары таләпләре нигезендә табибларны урнаштыру һәм табель мөлкәте белән тәэмин итү.

3.11. Янгын сүндерү төркеме үлгән хайваннарны яндырганда янгын куркынычсызлыгы чараларын үтәүне башкара.

Нурлат муниципаль районының ирекле янгын сүндерү командасы шоферы яндыру урынын сайлауда катнаша. Янгын чыккан очракта аны сүндерүне оештыра һәм үткәрә.

3.12. Санитар эшкәртү пункты шәхси составны һәм транспорт чараларын санитар эшкәртү һәм бер тапкыр кулланыла торган киемнәрне яндыру юлы белән юк итүне башкара.

Санитар эшкәртү пунктының шәхси составы шәхси составны һәм транспортны санитар эшкәртә, "ТКХ ИК" МУП хезмәткәрләреннән формалаша.

Нурлат муниципаль районының ирекле янгын сүндерү командасы шоферы яндыру Хайваннар һәм кешеләр авыруларын локальләштерү һәм бетерү буенча чаралар комплексы тәмамланганнан соң, отрядның шәхси составы һәм карантин зонасында

эшкә җәлеп ителгән затлар мәҗбүри санитар эшкәртү уза, ә бер тапкыр кулланыла торган махсус кием яндыру юлы белән юк ителә.

Пунктны җиһазлау: Комаровның дезинфекцион җайланмасы (күчмә душ җайланмалары яки ранецлы дезинфекцияле сиптергечләр), су савыты, сабын, сөлге, утын.

## 4. ОТРЯД КОМАНДИРЫ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

4.1. Отряд командиры эпидемия учагында эпизоотиягә каршы чараларны оештыру һәм үткәрү, отрядны шәхси состав һәм мөлкәт белән комплектлау өчен җавап бирә һәм йогышлы авырулар чыганагын бетерү буенча бурычларны үтәү чорында отрядның барлык шәхси составының турыдан-туры башлыгы булып тора.

4.2. Отряд командиры бурычлы:

– авыру чыганагында эпизоотиягә каршы чараларны оештыру һәм алып бару буенча җитәкче документларның таләпләрен белү һәм аларга үз эшчәнлекләрендә таяну;

– отрядның урнашу һәм эш итү районында ветеринария-санитария һәм эпизоотик хәлне өйрәнү;

– отрядның авыру чыккан урындагы хәрәкәтләргә әзерлеген арттыру һәм эшен камилләштерү буенча чаралар эшләү һәм оештыру;

– ветеринария хезмәтләре белгечләренә хайваннарның йогышлы авырулары белән эпизоотик хәл буенча, әлеге авыруларга каршы көрәш чаралары, зарарланган һәм зарарланган хайваннар белән эш итүдә шикләнелүчеләр белән эшләү, куркынычсызлык техникасы кагыйдәләре турында мәгълүмат бирүне оештыру;

– Нурлат муниципаль районының гадәттән тыш хәлләр комиссиясе рәисенең карантин салу турында карарын эшләү өчен тәкъдимнәр кертү турында;

– шәхси составны махсус әзерләүне оештыру һәм үткәрү;

– отряд бүлекчәләренең ихтыяҗларын билгеләү һәм белү;

– отряд өчен тиешле матди һәм дезинфекция чараларын вакытында соратып алу;

– матди чараларны исәпкә алу, саклау һәм куллануны контрольдә тоту;

– отрядның шәхси составы белән аны эпизоотик чыганакта хәрәкәтләргә әзерлеккә китерү буенча тренировкалар үткәрү;

– Нурлат муниципаль районының гадәттән тыш хәлләр рәисенә гадәттән тыш хәлләрне бетерү зонасындагы эпизоотик хәл турында мәгълүматларны үз вакытында тапшыру;

– отрядның шәхси составының функциональ бурычларын эшләүдә катнашу һәм аларны раслау;

– Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә карантинны бетерү буенча тәкъдимнәр бирү.

## 5. ОТРЯДНЫ ӘЗЕРЛЕККӘ КИТЕРҮ ТӘРТИБЕ

5.1. Сигнал алган мизгелдән отрядны әзерлеккә китерү өчен 2 сәгатьтән артык булмаган гомуми вакыт бирелә. Шул ук вакытта ветеринария разведкасы төркеме эпизоотик урынга бер сәгать эчендә барып җитә.

5.2. Отрядны әзерлек хәленә китерү буенча барлык чаралар да, шәхси составка хәбәр итү һәм җыю, комплектлаштыру һәм эпизоотик чыганакка чыгу вакытында отряд белән идарә итүне комплектлау, оештыруны да кертеп, отряд командиры карары буенча тормышка ашырыла.

5.3. Отрядның шәхси составын хәбәр итү һәм җыю өчен «Нурлат район дәүләт ветеринария берләшмәсе»ДБУнең кизү тору инструкциясенә күрсәтмә әзерләнә.

5.4. Бүлекчә командирлары җыелу урынына килеп җитү белән отряд командирына шәхси составның, автомобиль техникасының килеп җитүе һәм шәхси составның бурычларны үтәүгә әзерлеге турында хәбәр итәләр.

## 6. ШӘХСИ СОСТАВНЫ ӘЗЕРЛӘҮ

6.1. Отрядка кергән белгечләр штаттагы вазифалар буенча эшләү тәҗрибәсенә ия булырга тиеш.

6.2. Отрядның шәхси составын әзерләүнең төп методлары булып инструктор-методик дәресләр, гамәли күнекмәләр һәм өйрәнүләр тора.

Шәхси состав белән инструкторлык-методик дәресләрдә эпизоотик чыганакта эшләгәндә шәхси составның йогышлы авыруларын кисәтү, шәхси саклану чараларыннан файдалану кагыйдәләренә, шулай ук кеше һәм хайваннар өчен уртак булган аеруча куркыныч авыруларга каршы көрәш чаралары турында инструкцияләр таләпләрен һәм әлеге Нигезләмә таләпләрен җиткерүгә аерым игътибар бирелә.

Отрядның шәхси составы белән Инструктор-методик дәресләрне бүлекчә командирлары үткәрә.

Отряд командиры күнекмәләрне әзерләү, үткәрү һәм тикшерү өчен җавап бирә.

## 7. ОТРЯД ДОКУМЕНТЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ

7.1. Отрядта документларның тиешле исемлеге төзелә. Документларның бер нөсхәсе Нурлат муниципаль районының гадәттән тыш хәлләр комиссиясе рәисендә, икенчесе отряд командирында саклана.

7.2. Отряд командиры документацияне алып бару, документлардагы белешмәләрне дөрес рәсмиләштерү һәм вакытында төгәлләштерү өчен җавап бирә.

7.3. Отряд документлары исемлеге:

– эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряд оештыру һәм комплектлау турында Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты карары күчермәсе;

– отрядның оештыру-штат структурасы;

– төркем составы;

– отряд составына керә торган автомобиль техникасы исемлеге;

– эш һәм эштән тыш очракларда төркем командирларына хәбәр итү схемасы;

– отрядның шәхси составына хәбәр итү, аларны җыю буенча район дәүләт ветеринария берләшмәсенең кизү торучысы инструкциясе.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы
Башкарма комитетының 2019 елның 19 сентябрендәге
852 номерлы карарына
2 нче кушымта

# *Отрядның оештыру-штат структурасы*

**Ветеринария разведкасы төркеме** (ш/с 3 кеше, 1 берәмлек техника):

***– командир (РДВБ җитәкчесе урынбасары) – 1 кеше.***
– лаборант (РДВБ) – 1кеше.

**Командир (РДВБҗитәкчесе)** – 1 кеше.
җиңел автомобиль – 1 бер.

**Шәхси состав – 47 кеше.**
**техника – 17 бер.**

**Хайваннарны аулау һәм юк итү төркеме** (ш/с 5 кеше., 1 бер. техника):

***- төркем командиры (РДВБның баш табиб-эпизоотологы) – 1 кеше.***
– хайваннарны аулаучы (РДВБ) – 3 кеше.
– исәпкә алучы (РДВБ) – 1 кеше.
җиңел автомобиль (РДВБ) - 1 бер.

**Группа утилизации** (ш/с 8 кеше., 3 бер. техника):
– төркем командиры («ЖКХ ИК» МУП) – 1 кеше.
– яндыручы («ЖКХ ИК» МУП) – 3 кеше.

***– исәпкә алучы (РДВБ) – 1 кеше.***
– ветеринар-санитар эксперт (РДВБ) – 1 кеше.
– йөк машинасы йөртүчесе («ЖКХ ИК» МУП) – 1 кеше
–экскаватор йөртүчесе («ЖКХ ИК» МУП) –1 кеше
- җиңел автомобиль («ЖКХ ИК» МУП) - 1 кеше

**Медицина һәм эпидемиология разведкасы төркеме**
(ш/с 4 кеше., 1 бер. техника):
– төркем командиры (табиб-инфекционист РҮХ) – 1 кеше.
– белгеч (СЭС) – 1 кеше.
– фельдшер (РҮХ) – 1 кеше.
– йөртүче (РҮХ) – 1 кеше.
җиңел автомобиль (РҮХ) – 1 бер.

**Дезинфекция төркеме**
(ш/с 5 кеше, 2 бер. техника):
– командир (РДВБ табиб-эпизоотолог) – 1 кеше.
– фельдшер-лаборант (ветеринар РДВБ) – 1 кеше.
– дезинфектор (РДВБ) – 1 кеше.
– водитель-ветеринар (РДВБ) – 2 кеше
җиңел автомобиль – 1 бер.
ГАЗ-3309га көйләнгән дезинфекция установкасы ДУ-2 (РДВБ) – 1бер.

**Үткәрү режимын тәэмин итү төркеме** (ш/с 5 кеше, 2 бер. техника):
– төркем командиры (ЭЭБ) – 1 кеше
хәрәкәтне көйләүче (ЭЭБ) – 3 кеше
– йөртүче-дезинфектор (РДВБ) – 1 кеше
патруль-пост хезмәте автомобиле – 1 бер.
дезинфекция установкасы (РДВБ) – 1бер.

**Җәмәгать тәртибен саклау төркеме** (ш/с 6 кеше, 2 бер. техника):
– төркем командиры (ЭЭБ) – 1 кеше
– хезмәткәрләр (ЭЭБ) – 5 кеше
җиңел автомобиль (ЭЭБ) – 2 бер.

**Санитар эшкәртү пункты** (ш/с 5 кеше, 2 бер. техника):

***– пункт командиры («ЖКХ ИК» МУП)– 1 кеше***
– дезинфектор («ЖКХ ИК» МУП) 2 кеше

***– водитель («ЖКХ ИК» МУП)- 1 кеше***

***– водитель («ЖКХ ИК» МУП) - 1 кеше***
автоцистерна («ЖКХ ИК» МУП)– 1 бер.
грузовой автомобиль («ЖКХ ИК» МУП)– 1 бер.

**Врачебно-сестринская бригада**
(ш/с 4 кеше, 1 бер. техника):
– бригада командиры (врач РҮХ ) – 1 кеше

***– шәфкать туташы (РҮХ) – 2 кеше***
***– йөртүче (РҮХ) – 1 кеше***
***санитар автомобиль – 1бер.***

**Янгын сүндерү төркеме**
(ш/с 1 кеше,1 бер. техника):
– йөртүче-пожарный (ДПК) – 1 кеше
янгын сүндерү машинасы (ДПК) –1бер.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 19 сентябрендәге 852 номерлы карарына
3 нче кушымта

# Төркем составы

| № т/с | Организациянең исеме | Җаваплы кешеләр саны | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| 1. | «Нурлат район дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 17 | Оештыру-штат структурасы нигезендә (2 нче кушымта) |
| 2. | «Нурлат үзәк район хастаханәсе» ДАСУ | 7 | |
| 3. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Нурлат районы буенча бүлеге | 10 | |
| 4. | Нурлат муниципаль районының ирекле янгын сүндерү командасы | 1 | |
| 5. | «Татарстан Республикасы гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФБССОның Нурлат һәм Аксубай районнарындагы филиалы | 1 | |
| 6. | «ТКХ ИК» МУП (санитар эшкәртү пункты) | 11 | |
| **Һәммәсе:** | | **47** | |


Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы
Башкарма комитетының 2019 елның 19 сентябрендәге
852 номерлы карарына
4 нче кушымта

**Отряд составына кертелгән техника исемлеге**

| № т/с | Автомобиль һәм махсус техника тибы | Техника саны, бер. | Техника каян бирелә (оешма исеме) |
|---|---|---|---|
| 1. | Җиңел автомобиль | 4 | **«Нурлат район дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ** |
| | | 3 | **Россия Эчке эшләр министрлыгының Нурлат районы буенча бүлеге** |
| | | 1 | **«ТКХ ИК» МУП** |
| | | 2 | **«Нурлат үзәк район хастаханәсе» ДАСУ** |
| 2. | Йөк автомобиле | 2 | «ТКХ ИК» МУП |
| 3. | Автоцистерна | 1 | «ТКХ ИК» МУП |
| 4. | Экскаватор | 1 | «ТКХ ИК» МУП |
| 5. | Янгын сүндерү машинасы | 1 | **Нурлат муниципаль районының ирекле янгын сүндерү командасы** |
| 6. | ГАЗ-3309 шассиларында Ду-2 дезинфекция җайланмасы | 2 | **«Нурлат район дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ** |
| | **Һәммәсе:** | **17** | |

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы
Башкарма комитетының 2019 елның 19 сентябрендәге
852 номерлы карарына
5 нче кушымта

## Төркем командирларына эштә һәм эштә булмаган вакытта хәбәр итү схемасы




*Искәрмә* - бүлекчә командирлары шәхси составка хәбәр итү схемасы буенча хәбәр итәләр*

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 19 сентябрендәге 852 номерлы карарына
6 нчы кушымта

**«Нурлат район дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ отрядны әзерлек хәленә китерү буенча кизү торучы инструкциясе**

1. Отрядны әзерлек хәленә китерү Нурлат муниципаль районының гадәттән тыш хәлләр рәисе яки аны алмаштыручы зат карары буенча башкарыла ала.

2. «Нурлат район дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ кизү торучысы отрядны әзерлеккә китерү өчен команда (боерык) алганда журналда алынган мәгълүматның датасын һәм вакытын, кыска мәгълүматны (фамилиясе, исеме, атасының исеме), элемтә телефоны номерын теркәргә һәм бу хакта отряд командирына кичекмәстән хәбәр итәргә тиеш.

3. Отряд командиры отрядның шәхси составына хәбәр итү һәм җыелу буенча күрсәтмә бирә.

4. Кизү торучы шәхси составка хәбәр итүнең теркәлгән схемасы нигезендә хәбәр итүне гамәлгә ашыра.